| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **Нижнекамский городской**<br>**С О В Е Т** | **Түбән Кама шәһәр**<br>**С О В Е Т Ы** |
| 423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12<br>тел./факс (8555) 42-51-76, 42-47-06 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12<br>тел./факс (8555) 42-51-76, 42-47-06 |


**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 29** **2015 елның 15 июне**

**2014 нче елның 30 нчы октябрендәге 28нче номерлы «Түбән Кама шәһәрендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Түбән Кама шәһәрендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакындагы карары"на үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 03.12.2012 ел, №230-ФЗ Федераль закон нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2014 нче елның 30нчы октябрендәге 28нче карары белән расланган Түбән Кама шәһәрендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Түбән Кама шәһәрендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 7 нче пунктның «в» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «в) һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, шулай ук һәр алыш-биреш буенча җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча ул, аның хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) һәм әлеге алыш-бирешләр башкарылган акчалар алу чыганаклары турында;

1.2. 13нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «13. Муниципаль вазифа биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча алыш-биреш эшләре башкарылган акчалар чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, законнарда каралган тәртиптә Түбән Кама муниципаль районының «Интернет» челтәрендә, шулай ук

бу мәгълүматлар булмаган очракта, рәсми сайтта аларның запрослары буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары тарафына тапшырыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А. Р. Метшин